**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 09 » 04 2018 № 179а

Аксубаево

«Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә сайлау участокларын төзү турында» Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы, “Сәяси партияләр турында” Федераль законга һәм “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” 2012 елның 2 октябрендәге 157-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 7 өлеше, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә сайлау участокларын төзү турында» Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 17 гыйнварындагы 3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. “597 нче сайлау участогы” пунктын төшереп калдырырга.

1.2. «Татсунчел сайлау участогы № 598» пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

**«Татсунчеләй сайлау участогы № 598**

Татар Сөнчәләев ав., Тукай ур., 12 й., Татар Сөнчәләев авыл клубы, 4-04-98 телефоны

Сайлау участогы чикләренә Татар Сөнчәле авылы, Пионер бистәсе, Кызыл яр бистәсе, Понамаревка торак пунктлары керә.».

1.3. «Тархан №581 сайлау участогы» пунктын төшереп калдырырга

1.4. “580 нче Иске Илдерәк сайлау участогы” пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«580 нче Иске Илдерәк сайлау участогы**

Иске Илдерәк авылы, Совет урамы, 13 йорт, Иске Илдерәк мәдәният йорты, телефоны 4-47-30

Сайлау участогы чикләренә торак пунктлар керә: Иске Илдерәк авылы, Уткино бистәсе, Тарханка авылы.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://aksubayevo.tatarstan.ru бастырырга.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районын
Башкарма комитет Җитәкчесе С.Ю.Зайцев